**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5188**
**03.10.2022**

Башкарма комитетның «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» 2020 елның 19 маендагы 2314 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең жирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Законы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» 2020 елның 19 маендагы 2314 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2020 елның 4 сентябрендәге 4734 номерлы, 2021 елның 27 маендагы 3591 номерлы, 2022 елның 10 мартындагы 1218 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтада:

а) кушымтаның исемендә:

- «2.4-2.8» цифрларын «2.4-2.7» цифрларына алмаштырырга;

- «3.2-3.8» цифрларын «3.2-3.6, 3.8» цифрларына алмаштырырга;

б) 2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү идарәсенең Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.4, 2.5, 2.17, 3.2, 3.5, 3.8, 3.10, 3.11, 3.14, 3.15, 3.16, 3.17, 5.1, 5.2, 5.6 статьяларында күздә тотылган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары:»;

в) 4 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы административ-техник инспекция идарәсе» МКУның Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.1, 2.4 - 2.7, 2.17, 3.2, 3.3 - 3.5,3.8, 3.10, 3.16, 3.17 статьяларында күздә тотылган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары:»;

2) 2 нче кушымтада:

а) исемендә «19.4.1 статьясының 1 өлеше» сүзләрен «19.4.1 статьясы» сүзләренә

алмаштырырга;

б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенең Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.4 статьясының 1 өлешендә, 19.4.1 статьясында, 19.5 статьясының 1 өлешендә, 19.7 статьясында күздә тотылган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары:

- идарә башлыгы;
- идарә башлыгы урынбасары, икътисадый анализ һәм прогнозлау бүлеге башлыгы;
- идарә башлыгы урынбасары, торак-коммуналь хуҗалыгы һәм төзекләндерү бүлеге башлыгы;
- идарә башлыгы урынбасары, транспорт һәм элемтә бүлеге башлыгы;
- энергетика бүлеге башлыгы;
- юл хуҗалыгы бүлекчәсе мөдире.»;

в) 3 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

г) 5 пунктта «19.4.1 статьясының 1 өлеше» сүзләрен «19.4.1 статьясы» сүзләренә алмаштырырга;

3) 3 нче кушымтаны кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә.


2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 3 октябрендәге
5188 номерлы карарына
кушымта

Башкарма комитетның
2020 елның 19 маендагы
2314 номерлы карарына
3 нче кушымта




Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева